| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 август 2020 ел № 16

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан 2019 елның 29 октябрендәге 28 нче номерлы Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020елның 01 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының 2019 елның 29 октябрендәге 28 нче номерлы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

54 статьяның 1 абзацы, 39 статьяның 3 абзацы, 58 статьяның 1 абзацы, 57 статьяның 3 пункты, 10 статьяның 2 абзацы, 39 статьяның 2 пункты, 13 статья, 15 статьяның 3 пункты 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга;

34 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

34 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

29 статьяның 2 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

34 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре генә, акцияләренең 100 проценты (өлешләре) җирлек милкендә булган муниципаль унитар предприятие, муниципаль унитар предприятие тарафыннан гына тәэмин ителергә мөмкин»;

34 статьяның 11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Сарабиккол авылы, Киров урамы, 4а адресы буенча җирле үзидарә хакимияте бинасында, Киров урамы, 3а адресы буенча гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Пионер урамы, 45 адресы буенча «Сатурн - Урал» ҖЧҖ бинасында урнашкан стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми pravo.tatarstan.ru порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Сарабиккол авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Г.Р.Адельшина